СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 март, 2024 ел** **№ 391**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2024 елның 13 февралендәге 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 116 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне (31.01.2022 № 144, 07.06.2023 № 302, 21.11.2023 № 349 карарлары редакциясендә) Кушымта нигезендә 2 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

Биектау муниципаль районы
территориясендә муниципаль җир
контроле турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Контроль чара уздыру нәтиҗәсендә билгеләнгән контрольдә тотыла торган зат тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлегенең мәйданы, белешмәләре Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлеге мәйданына туры килмәве.

2. Контрольдә тотыла торган зат тарафыннан белешмәләре Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлегеннән фактта файдалану җир кишәрлегеннән файдалану максатынына туры килмәве.

3. Җир кишәрлеген бирү мизгеленнән өч елдан артык вакыт узу яисә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү срогы чыгу шарты белән җир кишәрлеген озак үзләштермәү, җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр күзәтелмәү (аннан рөхсәт ителгән файдалану һәм аны бирү шартлары нигезендә капиталь төзелеш объекты төзелеше, төзелеш эшләрен алып бару һәм җир кишәрлегеннән файдалану буенча башка гамәлләрнең булмавы).

4. Җир кишәрлекләреннән файдалану өчен нигез булып торган документларны рәсмиләштерүгә карата мәҗбүри таләпләрне үтәмәү.